**Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарны торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән катнашучылар исемлегенә, шулай ук торак урынны наем шартнамәсе буенча авыл территорияләрендә торак төзелеше (сатып алу) чараларында катнашучылар исемлегенә кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында " 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә, Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарны торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән катнашучылар исемлегенә, шулай ук торак урынны наем шартнамәсе буенча авыл территорияләрендә торак төзелеше (сатып алу) чараларында катнашучылар исемлегенә кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.
2. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 07.09.2022 № 563 карарын үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Ф. Әхмәтшинга йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**